ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексына
үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 өлешендәге утыз сигезенче абзацында «калдыклар исәбе» сүзләреннән соң «федераль» сүзен өстәргә;

2) 93 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Сазлыкларны җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычрату һәм чүпләү, аларны нефть продуктлары һәм башка пычраткыч матдәләр, шулай ук пестицидлар белән пычрату тыела.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Сазлыклардан аерым максатларда файдалану үзенчәлекләре федераль законнар нигезендә билгеләнә.»;

3) 99 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Махсус сакланылучы аерым су объектларыннан файдалану үзенчәлекләре федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 91-ТРЗ